
Газета МБОУ «АСОШ №2»

# Пульс школы
# Мәктәп пульсы



№1
Сентябрь, октябрь 2019 г.

## Счастье только знающим дано!

**Первое сентября считается особым днем. Его называют днем знаний. Именно в этот день тысячи школьников сели за парты—начался процесс постижения знаний, получения новой информации, которая станет надежным попутчиком в жизни.**



**Дорогие ребята,**
**уважаемые учителя!**

С огромным удовольствием я поздравляю всех собравшихся с Днем знаний, с 1 сентября! Позади долгие летние каникулы, во время которых все мы успели как следует отдохнуть. И сейчас с новыми силами мы готовы приступить к учебе и работе. Сегодня мне бы хотелось пожелать удачи ученикам и учителям. Надеюсь, что грядущий школьный год будет интересным, насыщенным событиями, полным новых побед и свершений!

***Гульназ Гиниатуллина,***
директор школы.

## Интересно знать!

- Улитка спит 3 года.
- Самая сильная мышца в теле – язык.
- Тигры имеют полосатую кожу, а не только полосатый мех.
- У морской звезды нет мозга.
- Гигантский кальмар имеет самый большой глаз в мире.
- Кожа белого медведя черная. Его мех не белый, а прозрачный.

**Уважаемые ветераны!**
**Сердечно поздравляем вас с Днем пожилых!**

Будьте всегда одарены заботой, уважением, пониманием не только близких, но и окружающих людей. Пусть в душе живет гармония, а в сердце поют соловьи. Пусть будет время и повод для любимых дел, отдыха и наслаждения жизнью.
Пусть родные любят и почитают вас!



## В этом выпуске:


| | |
|---|---|
| Болгар легендасы: ышаныргамы, юкмы? | 2 |
| Без - Тукай оныклары! | 3 |
| Отдыхали на берегу Гаспра... | 4 |
| Каникулдан каникулга... | 4 |
| 18 яшь: бәйсезлек һәм җаваплылык | 5 |
| Вечная память Марату Лотфуллину! | 6 |

# Болгар легендасы: ышаныргамы, юкмы?

**Туристларны дөньяның төрле почмакларына җәлеп итәр өчен экскурсоводлар төрледән-төрле легендалар, риваятьләр уйлап чыгара.**

Бөек Болгарга сәяхәт кылганда, билгеле, үземә дә әкияткә тиң легендалар ишетергә туры килде. Иң кызыклы дип тапканнарын бер язмага туплап, аларга карата танышларымның мөнәсәбәтен дә сораштырдым әле.

***Үрдәк сурәте***

Элек-электән кайбер хайваннарны аеруча ихтирам иткәннәр, алар арасына үрдәк тә керә. Легендаларга ышансаң, Болгар ханлыгында гап-гади үрдәкләрне җир табучылар дип атаганнар. Борынгы тәлинкәләрдә аларның сурәтләре еш күренүе – шуңа дәлил.

**Динә Нәҗметдинова:**

-Мин җир шарының зур шартлау рәвешендә барлыкка килгән, - дип әйтүчеләр сүзенә ышанам. Андабашта су гына булган. Тора-бара туфракбарлыкка килгән, дип уйларга кирәк. Шул вакыт очраклы рәвештә судан үрдәк чыгып, әлеге яңалыкның шаһиты гына булгандыр (Көлә).

***Кара пулат***

Чыңгызхан оныгы Булаттимер Болгарны басып ала һәм анда урнашканбер пулатны яндырырга карар кыла.Һәм шул кап-кара төтен эченнән чыккан гаҗәеп матур бер кызга үзенә кияүгә чыгарга тәкъдим итә. Тиккызәлеге карарны кире кага. Булаттимер анынәнеләрен алып килеп, аларга үлем җәзасы янаганы турында әйтә. Кыз бер шарт белән генәкияүгә чыгарга ризалаша: Булаттимер аның энеләрен иң җитез атларга утыртып җибәрергә тиеш була. Бертуган энеләр шактый еракка киткәч, әлеге кыз бина башыннан сикереп, һәләк була. Бу үлем кара төсне хәтерләткәнгә, шушы пулатны да Кара пулат дип йөртә башлыйлар.

**Зөләйха Зәбирова:**

-Музейларда экскурсовод ларны тыңлап йөрергә яратмыйм, тик мавыктыргыч Болгар легендаларын күпме генә ишетсәм дә, авыз ачып диярлек тыңлыйм. Минемчә, борынгы заманнарда әлеге хәл чынлап та була алгандыр. Тик кызның төтен эченнән чыгуы гына ялган кебек тоелды. Ә кыз урынында булсам, мин дә туганнарым бәхете өчен күкләргә менәр идем.

***Табибка һәйкәл***

Кышның зәмһәрир суыкларында Алмыш ханның яраткан кызы авырый башлый.Аны иң абруйлы табиблар карап чыккач, дәвалау өчен каен себеркесе һәм чиста чишмә суы кирәклеген беләләр. Шул вакытта аларның берсе, казыгын җиргә кагып, каен агачын үстерә, ә аның тамырларыннан чишмә бәреп чыга. Ул кызны терелтә һәм шуның өчен аңа өйләнергә була. Яшьләр, өйләнешеп, тигез гомер итәләр. Болгар музей-тыюлыгының табиб җирләнгәнурынына каләм, түбәтәй һәм казык сурәтләнгән һәйкәл куялар. Бүген шушы истәлекле урынны һәркем килеп күрә ала.

**Айзилә Сабирова:**

Мондый хәлнең булуына ышанып бетмим, риваять бу. Моның кадәр кыю каһарманнар, булмый. Нинди генә авыр хәлдә калуыма карамастан, әлеге кыз урынында булсам, мине коткарган кеше белән бар байлыгымны бүлешеп, аңа һәрчак рәхмәтләр укып яшәр идем. Тик кияүгә чыкмас идем. Чын мәхәббәт бер танышуда гына барлыкка килә алмый бит.

**Автордан:**

Легендалар һәркемнең күңеленә хуш килгәндер. Дөреслеккә туры килү-килмәвен, дустым, үзеңә хәл итәргә туры килер.

**Рүзәл ШӘРИПОВ**, 10 сыйныф



# Без — Тукай оныклары!

**Быелгы җәйге ялым «Без-Тукай оныклары» чатырлы аланда күңел ачу белән истә калды. Күп кенә бәйгеләрдә актив катнашып, күп көч түгеп укыганнан соң менә дигән ял булды бу!**

Әлеге алан дуртенче ел рәттән Арча районында уздырылып килә. Быел да биредә Башкортстаннан,Удмуртиядә, Киров, Оренбург өлкәләреннән, Мари Иленнән, Татарстанның төрле районнарыннан 200ләп сәләтле бала җыелды. «Без - Тукай оныклары» аланы-татар теле мохитендә яшәү генә түгел, аның мөмкинлекләрен ачу да. Без, татар телен, әдәбиятын яраткан, аның үсеше һәм камилләшүе турында кызыксынган, кайгырткан балалар, үзебезне Тукай оныклары дип горурланып атый алабыз!

Ялыбызны оештыручылар безгә бик кызыклы программа әзерләгәннәр. Һәркем үз күңеленә якын булган юнәлештә шөгыльләнә алды. Әйтик, фолкьлор, бию, музыка уен коралларында уйнау, рәсем ясау, тубәтәй, калфак чигү.Мондагы тормыш осталык дәресләре белән генә тәмамланмый әле. Кызыклы чаралар, аралашулар, күңелле кичәләр, төрле бәйгеләр белән аралашып барды. Мәгарифне үстерү институты, Казан Федераль университеты галимнәре,язучылар Вакыйф Нуриев, Камил Кәримов, “Казан утлары”, Салават күпере”,”Сәхнә” журналы журналистлары,“Талантлар Университетыннан” остазлар кайтып, безгә күңелле мастер-класслар, уеннар уткәрделәр, татар радиостанция челтәреннән Фәннур Фаттахов, Гаяз Гайсин белән очрашу безгә аеруча ошады. Шулай ук без Яңа Кырлай авылында урнашкан Габдулла Тукай музеена экскурсияләргә бардык.

«Без - Тукай оныклары» аланында гына шәп атмосфера, кызыклы кичке чаралар, иң тәҗрибәле укытучылар җыелган. Биредә узучы дәресләр, остаханәләр бик үзенчәлекле һәм кызыклы булды.

-Әгәр дә сез смена дәвамында үзегезне бәхетле хис итәсез икән, бу безнең өчен иң зур бәхет һәм чын ләззәт! Еракларда агылып килгәнегез өчен рәхмәт сезгә, дуслар! Әйдәгез, рәхәтләнеп ял итик, күңел ачыйк, җырлыйк, биик. Табигать бүләк иткән матур, ямьле җәйнең кадерен белик! Позитив һәм креатив яшьләр - аланның чын дуслары!

Арчаның шифалы һавасыннан, назлы кояшыннан ел дәвамына җитәрлек көч туплап, аны файдаланып, башкаларны да илһамландырырга язсын сезгә! - диде оештыручылар.

Бу шулай булды да: соры көннәрне кояшның назлы елмаюы алыштырды. Ул безгә көләч йөзе белән елмаеп, безнең күңелләрне күтәрде.

Кыскасы, «Без - Тукай оныклары» аланы бер атна дәвамында татар теле мохитендә яшәтте, тел байлыгын арттырды, дуслаштырды. Иң сәләтле яшьләр өчен күңел ачу мәйданчыгы буларак хезмәт итте. Әгәр киләсе җәеңне дә мәңгегә онытылмаслык вакыйгалар белән бизисең килә икән, безгә кушыл!

**Ралинә МӨХӘММӘТГАЛИЕВА,**

5Б сыйныфы



# Отдыхали на берегу Гаспра...



Этим летом я побывал в Республике Крым, это небольшой полуостров, граничивший с Украіной, но сам Крым принадлежит Росси уже с 2014 года. Для поездки туда и обратно нам понадобилось 2 дня. Отдыхал я в Крыму в небольшом посёлке Гаспра.

Климат здесь очень жаркий. Ехав вдоль побережье Крыма, я любовался дивной красотой. Так как Крым горная местность, здесь было много высоких гор, одной из которых является гора Аюдак, такое название она получила из-за своей необычной формы. Приглянувшись на неё, можно увидеть опущенное вниз тело медведя.

Приехав в Гаспру, я сразу обратил внимание на море, ведь оно было таким продолговатым, также здесь как мы уже привыкли вместо пальм растут кипарисы. Выгрузив все свои вещи в дом, я начал осматривать местность, выйдя из дому можно было бесплатно поесть растущий виноград и дикий инжир, их в Гаспре было очень много. Позже мы были уже на пляже, погода тогда была жаркой и мы решили искупаться, вода тоже была очень благоприятная. Первые 2-3 дня были обычными.

Коренными жителями всего Крыма были крымские татары, у них мы тоже побывали. Их местность располагалась в основном в на вершине горы или у подножия. Мы же как и все по канатной дороге устремились в гору. Гора называлась Ай-Петри мне там тоже очень понравилось. На горе мы познакомились с многими крымскими татарами их язык и был похож на наш татарский. Из-за этого мы могли с ними свободно разговаривать на нашем татарском языке. Еще мы немного покатались на верблюдах.

Главным символом Крыма является Ласточкино гнездо, там мы тоже побывали и увидели не мало удивительного. Кроме Ласточкиного гнезда мы были в Воронцовском дворце, там было необычайно красиво, а больше в этом дворце мне понравился музей восковых фигур. В музее я увидел и услышал о многих людей связанных с нашей историей, от Ивана Грозного до последнего человека династии Романовых.

В предпоследний день нашего путешествия я посетил легендарный город Севастополь. То что я увидел не в сказке сказать, не пером написать. Своей душой я чувствовал, что весь город пропах историей.

Во-первых. в 1853 году здесь проходила Крымская война, 3 страны: Турция, Англия, Франция. Эти страны напали на город, лишь один Севастополь держал оборону. В этой схватке себя проявил легендарный адмирал П.С.Нахимов. Говорили, что нет незаменимых, но он был.

Во-вторых, здесь проходила ВОВ (1941-1945). Красная армия ели отбила у немцев это город

Также проходя этот город, я увидел ВМФ РФ. Памятников здесь тоже не мало, одной из которых является памятник затонувшим кораблям. Был ещё памятник моряку и солдату, оборонявшему Севастополь.

Ещё я зашел в исторический музей Севастополя и увидел там понораму сражения Крымской войны.

В итоге могу сказать, что поездка мне очень понравилась!

**Азат Исмагилов,** *8Б класс*

# Каникулдан каникулга...

***Ислам МИНГАЗОВ:***

Җәйнең беренче көнен озак итеп йокلармын дигән план барып чыкмады.Тиешле вакыт җитүгә күз шардай ачылды. Каникулның беренче көне шулай башланып китте. Җәйге ритмга бик тиз ияләндек. Елга суларында коендык, тәмле җиләкләр ашадык, балык тоттык. Тагын әби белән бабайга булыштык.

Җәйнең иң истәлекле көне - ул минем туган көн.Ул көнне мин тизйөрешле велосипедка ия булдым. Ямьле җәй, шул велосипедта йөргән кебек үтте дә китте. Инде киләсе җәйне көтәбез!

***Камил ГАРИФУЛЛИН:***

Туган ягыма көз килде, көннәр бераз салкынайды. Агачларның яфраклары сары төскә кереп шыбыр-шыбыр җиргә коелалар.

Безнең беренче чирек тәмамлана. Тиздән каникуллар башлана.

Мин әнием белән бергә Казанга барырга уйлыйм. Аннан кайткач, авылга дәү әнием янына кайтам. Эш беткәч, без бергәләп китаплар укыйбыз, дамино уйныйбыз.

Без әбием белән паркта ял итәргә дә яратабыз, төрле уеннар уйныйбыз. Сары, кызгылт яфраклар җыеп, букет ясыйбыз.

Мин бу каникулымны да матур итеп уздырырга уйлыйм.

**6А,Б сыйныфы**

# 18 яшь: бәйсезлек һәм җаваплылык

**Тормышымдагы беренче мөһим тавышны ничек бирәсе һәм, гомумән, 18 яшь тулгач, нинди хокуклар барлыкка киләчәк?**

Күптән түгел республикабызда грандиоз сайлаулар булып узды. Быелгы сайлауда катнашмасам да, Дәүләт Советына киләсе чакырылыш депутаталарын сайлаганда, миңа да тавыш бирергә туры киләчәк дип уйлыйм.

Барыбызга да мәгълүм булганча, 18 яше тулган һәркем сайлауларда, референдумнарда катнашу хокукына ия, чөнки балигъ булганннар хезмәткә тулысынча яраклы кешеләр рәтенә керә.

Әле алай гына да түгел, 18 яшьтән башлап син үзең дә дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарында эшләргә дәгъва кыла аласың. Әлеге һәм башка мөмкинлекләр белән якыннанрак таныштырыр өчен, барысын да тәфсилләп сөйләрмен.

Тавыш бирү билгеләнгән көнне син, яшәү урының буенча сайлау участогына килеп, комиссия вәкиленә паспортыңны тапшырырга тиеш. Имзаң куелып, барлык мәгълүматлар да тикшерелеп беткәч, сиңа бюллетень бирелә.

Анда тәкъдим ителгән кандидатларның исем-фамилиясе һәм аларны тәкъдим иткән сәяси партияләр турында кирәкле мәгълүмат языла. Танышып чыккач, исемлектән бер кешене сайлап бюллетеньне аерым бер тартмага салырга кирәк.Шуның белән тавыш бирү тәмамлана! Сайлауда беренче катнашучыларга истәлекле бүләкләр дә каралган!

Тик 18 яшь тулу белән сайлау хокукыннан кала синең җилкәңә тагын бер кочак хокук һәм бурычлар ята. Закон таләпләрен үтәү иң мөһимнәрдән санала, чөнки балигъ булганнарга карата җинаять җаваплылыгы тулы дәрәҗәдә эшли башлый.

18 яшь тулганнар сәяси партияләргә һәм иҗтимагый берләшмәләргә керү мөмкинлегенә ия, ә күпләре мондый берләшмәләрне үзләре гамәлгә дә куя алалар. Мондый төр оешмаларга акчалата ярдәмне дә син шушы вакыттан бшлап кына күрсәтә аласың.

Балигъ булганнарга барлык дәүләт органнары каршында үз фикерләрен мөстәкыйль рәвештә якларга кирәк. Ягъни барлык кәгазь эшләрен син үзең башкарырга тиешсең.

15 яшьлек балага нинди дә булса килешү төзү авырдан килергә мөмкин, чөнки, билгеле булганча, барлык финанс оешмалары да балигъ булмаганнар белән эшләргә әзер түгел. Тик 18 яшь тулу белән син килешүләр төзи, Россиянең теләсә кайсы банкы яисә идарәче компаниясенең клиентына әйләнә аласың.

Синең исемеңә машина яки фатир язылган икән, алар өчен син мөстәкыйль рәвештә салымнар түләргә тиеш.

18 яшь тулганнар шулай ук гаилә кору хокукына да ия, тик ул вакытка булачак яшь парлар туганлык җепләре белән бәйләнмәгән булырга тиеш. Балигъ булганнар әти-әниләреннән һәм опека органнарыннан башка гына эшкә урнаша яисә шәхси эшмәкәр буларак теркәлеп, бизнес алып бара ала. 18 яшьтән әти-әни рөхсәтеннән башка чит илгә ирекле рәвештә чыгарга мөмкин, тик визаны да мөстәкыйль рәвештә алырга туры киләчәк.

Мопедлар һәм кайбер мотоцикллар белән идарә итү хокукын инде 16 яшьтә үк алып була, ә менә A, B, C һәм B1, C1 категорияле машина йөртү таныклыгын бары тик 18 яшьлекләргә генә бирәләр.

Хокуклардан кала мөһим бурычың бар икәнен дә онытa күрмә: 18 яше тулган һәр сәламәт ир-егет 12 ай дәвамында армия сафларында хезмәт итәргә тиеш.


18 яшь тутырып, олы тормышка аяк басу – бик дулкынландыргыч һәм җитди адым. Тормыш әзерләгән барлык сорауларга җавапларны син мөстәкыйль рәвештә эзләсәң дә, әти-әниеңнең зирәк фикерләренә колак салу да зарур, чөнки балигъ булуга берьяклы карасаң гына, бәйсезлек булып күренә...

**Автордан:**

11 нче октябрь көнне безнең мәктәптә дә президентка сайлау булды. Бу хакта тулырак киләсе санда яктыртылачак.

***Рүзәл Шәрипов,***

*10 нчы сыйныф*



# Вечная память М.Лотфуллину!



6 сентября в нашей школе, в рамках осенней недели доброты, под руководством учителя ОБЖ Ильдуса Аскарова прошла мероприятия у Мемориала памяти Марата Лотфуллина, война-авганца, выпускника школы. Погибшего вовремя исполнения интернационального долга, и посмертно награжденного Орденом красной звезды.

В рамках данного мероприятия отряд юнармейцев нашей школы навестил могилу М.Лотфуллина на Татарском кладбище г.Арск, где ребята возложили венки к могиле воина и услышали рссказ о его судьбе.

# Мы с кружком в гостях...




17 сентября,мы, члены кружка “Юный журналист”, под руководством Расимы Ибраевой ходили в редакцию газеты “Арский вестник” Нас там встретил редактор газеты Исрафил Насибуллин. Он рассказал нам историю газеты. А также ознакомил с колективом газеты. Они настоящие профессионалы, талантливые журналисты. У них богатый опыт, твердая жизненная позиция, трудолюбие.

Нам эта встреча очень понравилась!

# Китап турында кыйсса

Бу елны Ринат алтынчы класска килде. Дәресләкләр өлешкәндә укытучы әйтте: «Бу яңа китаплар, аларның битләрен ертмагыз, бөкләмәгез, карандаш һәм ручка белән язмагыз, юешкә куймагыз!». Ринат икенче көнгә дәрескә килде. Китапларның яңа дип әйтерлеге дә калмаган: беренче битенә үк язылган да, бер бите ертылган да иде. Житмәсә, өйгә кайткач, ул аларны су белән «коендырган».

Менә өч ел вакыт үтте. Ринатның кечкенә сеңлесе Мәликә алтынчы класска да житте. Аларга да укырга китаплар бирделәр. Мәликәгә иске китап эләкте. Аның артында, Дюркиев Ринат 6Б, дип язылган иде. Мәликә өйгә кайтып китапны әнисенә күрсәтте. Әнисе Ринатка да Мәликәгә дә алай ярамаганны анлатты. Ринат сеңлесенә китапны бик тырышып-матурлап бирде һәм башка алай эшләмәскә әнисенә сүз бирде.

**Карина ЖАМАЛИЕВА ,** *6 Б сыйныфы*

**Редактор** учитель татарского языка и литературы Ибраева Р.Х.

***Дизайнер - верстальщик*** Азат Исмагилов
Ислам Сафиуллин

***Фотокорреспондент*** Азамат Файзрахманов

***Корректор*** Адиля Габдуллина

***Редколлегия*** Ислам Габдрахманов
Камиль Гарифуллин

***Адрес:*** ул. Мост овая, дом 15